СОВЕТ БУРБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӨРБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» марта 2019 г. № 114

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге 2018 елның 20 декабрендә кабул ителгән 105 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджет турында " карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегенең баш хисапчысының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борбаш авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 2021 еллар план чорына бюджетына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлап, фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 декабрендәге 105 номерлы " Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты турында» карарына үзгәрешләр һәм остәмәләр кертү хакында:

1. Статья 1не түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2019 елга Бөрбаш авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге бюджетының фаразланыла торган гомуми керем күләме 2 307,9 мең.сум;

2) Бөрбаш авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгым күләме 2 382,9 мең сум;

3) бюджет чыгымнары күләмен арттыру Бөрбаш авыл җирлегенең исәп хисап счетында ирекле калган акчалар хисабына 2019 елның 1 гыйнварына 75,0 мең сум күләмендә башкарырга;

4) Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегенең бюджет дефициты 75,0 мең.сум;

2. Кушымталар №1,3,8,10 яңа редакңиядә бәян итәргә (бирелә).

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән һәм мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бөрбаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Галимуллин